ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.06.2019 Олы Кайбыч авылы №265

Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017елның 04 июлендә чыккан 788номерлы «Төзелешкә рөхсәт һәм файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны электрон рәвештә җибәрү турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 27сентябрендә чыккан 2017елның 729номерлы «Төзелешкә һәм эксплуатациягә рөхсәт бирү документларын электрон формада җибәрү турында» карарын үтәү йөзеннән, 2017 елның 29 декабрендәге 479-ФЗ санлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрдә гариза бирүче тарафыннан бер генә гариза бирү юлы белән берничә дәүләт (муниципаль) хезмәте күрсәтү мөмкинлеген беркетү өлешендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019елның 29маенда чыккан 254номерлы «Архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Муниципаль хезмәтләр түбәндәге Федераль законнар нигезендә күрсәтелә:

2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ санлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – РФ ШтК) (РФ Законнар җыентыгы, 03.01.2005, № 1 (1 өлеш), 16б);

2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ санлы Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ЖК) (РФ Законнар җыентыгы, 29.10.2001, № 44, 4147 м.);

"Россия Федерациясендә архитектура эшчәнлеге турында" 1995 елның 17 ноябрендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 169-ФЗ номерлы

Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 20.11.1995, №47, 4473 м.);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ санлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 06.10.2003, № 40, 3822 м.);

06.04.2011 чыккан 63-ФЗномерлы «Электрон имза турында» Федераль законы (РФ Законнар жыентыгы, 11.04.2011, № 15, 2036м.);

Россия Федерациясе Президентының 07.05.2012 чыккан 601номерлы «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Указы (РФ Законнар җыентыгы, 07.05.2012, № 19, 2338м.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 26.03.2016чыккан 236номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә таләпләр турында» Карары (РФ Законнар җыентыгы, 11.04.2016, № 15, 2084м.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 04.07.2017чыккан 455номерлы «Төзелешкә һәм эксплуатациягә рөхсәт бирү документларын электрон формада җибәрү турында» (РФ Законнар җыентыгы, 10.07.2017, № 28, 4162м.);

Россия Минстроеның 19.02.2015 чыккан 117/пр номерлы «Төзелешкә һәм эксплуатациягә рөхсәт бирү формасын раслау турында» Приказы (хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 13.04.2015);

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы ТР Законы (алга таба – 45-ТРЗ санлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 27сентябрендә чыккан 2017елның 729номерлы «Төзелешкә һәм эксплуатациягә рөхсәт бирү документларын электрон формада җибәрү турында» карары (РФ Законнар җыентыгы, 20.10.2017, № 728, 4162м. );

15.11.2018 чыккан 136 номерлы карар белән Кайбыч муниципаль район советы кабул иткән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав);

13.04.2013 чыккан 168 номерлы Кайбыч муниципаль районы Советы раслаган Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы нигезләмә (алга таба – БК турындагы Нигезләмә) ;

Башкарма комитет җитәкчесенең 20.06.2014 чыккан 296 номерлы бүлек турында расланган нигезләмәсе; (алга таба – бүлек турында Нигезләмә);

Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан расланган, 16.02.2015 чыккан б/н номерлы эчке хезмәт тәртибе турында кагыйдәләр. (алга таба – Кагыйдәләр).

1.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорау аңлашыла (27.07.2010 ел, №210-ФЗ Федераль законның 2 ст 2 пункты). Гариза стандарт бланкта (1нче кушымта) тутырыла.

Төзелешкә рөхсәт мондый рөхсәт төзелешнең аерым этапларына, реконструкциягә бирелүдән тыш, капиталь төзелеш объекты проекты белән каралган бар срокка бирелә. Индивидуаль торак төзелешенә рөхсәт ун елга бирелә.

Төзелешкә рөхсәт мондый очракларда таләп ителми:

1) физик затка эшмәкәрлек максатларында булмаганда гараж төзү өчен, яки бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару өчен бирелгән җир кишәрлегендә;

2) капиталь төзелеш объекты булмаган объектлар төзелешенә, реконструкциясенә, (киоск , навес һ.б.);

3) җир кишәрлегендә ярдәмче куллану корылмалары төзегәндә;

4) капиталь төзелеш объектын һәм (яки) аның өлешләрен үзгәртү, мондый үзгәрешләр куркынычсызлыкның конструктив характеристикаларын бозмаган һәм Шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән төзелеш, реконструкция параметрлары чикләрен узмаган очракта;

5) капиталь төзелеш объектлары капиталь ремонтына;

6) РФ ШтК Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге белән бәйле канунчылыгы нигезендә рөхсәт бирү каралмаган башка очракларында;

7) Төзелешкә рөхсәт срогы бу срок чыгарга алтмыш көн алдан бирелгән застройщик гаризасы нигезендә Башкарма комитет тарафыннан озынайтылырга мөмкин. Әгәр бу срок чыкканчы эшләр башланмаган булса, срок озынайтылмый.

8) Әлеге регламентта түбәндәге атама һәм билгеләмәләр файдаланыла:

- ЕСИА – идентификация һәм аутентификациянең бердәм системасы;
- гариза–муниципаль хезмәт күрсәтүне сорау;
- гариза бирүче - Башкарма комитетка дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап телдән, язмача яки электрон формада мөрәҗәгать иткән физик яки юридик зат ( дәүләт органнары һәм территориаль органнар, дәүләт бюджеттан тыш фондлар органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнарыннан кала) яки аларның вәкаләтле вәкилләре, "Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүне раслау турында" Федераль законының 15.1 статьясы нигезендә ;

-застройщик – үз милкендәге яки башкалар милкендә булган җир кишәрлегендә төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектларын сүтү , шулай ук бу эшләр өчен проек документациясе әзерләү, инженер эшләрен башкаруны тәэмин итүче физик яки юридик зат. Застройщик шәһәр төзелеше эшчәнлеге белән бәйле канунчылыгы белән аңа каралган функцияләрне техник заказчыга тапшыра ала;

-техник заказчы - юридик зат, застройщик исеменнән проек документациясе әзерләү, инженер эшләрен башкару буенча, төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектларын сүтү буенча килешүләр төзи, әлеге төр эшләрне башкаруга заданиеләр әзерли , проек документациясе әзерләү, инженер , төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектларын сүтү эшләрен башкаручы затларга материаллар һәм документлар әзерли, проект документациясен раслый, капиталь төзелеш объектын эксплуатациягә кертү өчен кирәкле документларны имзалый, шәһәр төзелеше эшчәнлеге белән бәйле канунчылык белән каралган башка функцияләрне үти. (алга таба - техник заказчы функцияләре). Техник заказчы функцияләре, РФ ШтК ның 2.1 өлеше

47 статьясы, 4.1өлешенең статьясы 48, 2.1 һәм 2.2 өлешләре 52 статьясы, 5 һәм 6 өлешләренең 55.31 статьясы белән каралаган очраклардан тыш , инженер эшләре, архитектур –төзелеш проектлаштыру, төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектларын сүтү өлкәсендәге үзкөйләүле оешма тарафыннан гына башкарыла ала;

2 ) 2.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | 1. Капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкциягә рөхсәт.<br>2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар.<br>Гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы uslugi.tatarstan.ru аша бирелсә, муниципаль хезмәт электрон формада күрсәтелә. |

3) 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатылу мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы | Төзелешкә рөхсәт бирү - гариза бирү көнен дә кертеп 5 көн.<br>Төзелешкә рөхсәт бирүгә үзгәрешләр кертү – 5 эш көненнән артмый.<br>Төзелешкә рөхсәт бирү дубликатын бирү – уч көн.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү срогын туктату каралмаган. |

4) 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон чыгаручы яки бүтән норматив хокукый актлар нигезендә зарури документларның, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен<br>кирәкле һәм мәҗбүри булган мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә тиешле хезмәтләрнең, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу, шул исәптән электрон рәвештә алу, аларны бирү ысулларының тулы исемлеге | Капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкция максатларында (шул исәптән мәдәни мирас объектын , шулай федераль яки региональ мәгънәгә ия тарихи җирлек территориясе чикләрендә капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү планлаштыру очрагында) застройщик:<br>1) гариза<br>- кәгазь формада;<br>- электрон формада (искәрмә: гариза бирүче исеменнән эш итүче затлар,) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы uslugi.tatarstan.ru ашабирелгән, №63-ФЗ Федераль закон һәм №210-ФЗ Федераль закон нигезендә гади электрон имза белән имзаланган; |

| | |
|---|---|
| | 2) гариза бирүче шәхесен раслаучы документлар, яки аның ЕСИАдан алынган реквизитлары, (электрон формада тутырылса);<br>3) гариза бирүче вәкиле шәхесен раслаучы документлар яки аның скан-копиясе (электрон формада тутырылса);<br>4) җиргә хокукны раслаучы документлар , әгәр алар Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса яки аның скан-копиясе (электрон формада тутырылса);<br>5) Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән очракларда, дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджеттан тыш фондлар белән идарә итү органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда төзелгән дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен тапшыру турында килешенү (булганда);<br>6) күрсәтелгән килешенүне төзегән хокукка ия затның җир участогына хокукын билгеләүче документлары;<br>7) проект документларындагы материаллар:<br>а) аңлатма язуы яки аның сканерланган күчермәсе (электрон рәвештә тутырганда);<br>б) капиталь төзелеш объекты, аңа килү һәм керү юллары, җәмәгать сервитутларының эш итү зоналарының чикләре, археологик мирас урнашкан урынны билгеләп, җир участогын шәһәр төзелеше планында күрсәткән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир участогын планлаштыруны оештыру схемасы яки аның сканерланган күчермәсе (электрон рәвештә тутырганда);<br>в) линия объектының линия объектларына карата кулланыла торган территорияне планлаштыру буенча документлар составында расланган кызыл линияләр чикләрендә урнашуын раслаучы җир участогын планлаштыруны оештыру |

| | |
|---|---|
| | схемасы яки аның сканерланган күчермәсе (электрон рәвештә тутырганда);<br>г) архитектура карарлары яки аларның сканерланган күчермәләре (электрон рәвештә тутырганда);<br>д) инженерлык җиһазлары турында мәгълүматлар, проектлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын инженерлыктехник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) урыннарын билгеләп, инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең җыелма планы яки аларның сканерланган күчермәләре (электрон рәвештә тутырганда);<br>е) капиталь төзелеш объектын төзүче оешма проекты яки аның сканерланган күчермәсе (электрон рәвештә тутырганда);<br>ж) капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен җимерү яки демонтажлау буенча эшләрне оештыручы оешманың проекты яки аның сканерланган күчермәсе (электрон рәвештә тутырганда);<br>з) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсе нигезендә, күрсәтелгән объектларның проект документларына экспертиза үткәрелмәү шарты белән күрсәтелгән объектлар төзелгән, реконструкцияләнгән очракта, инвалидларның сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт объектларына һәм социаль-мәдәни һәм коммуналькөнкүреш билгеләнештәге башка объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эш, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына керүен тәэмин итү буенча чаралар исемлеге яки аның сканерланган күчермәсе (электрон рәвештә тутырганда);<br>8) әгәр мондый проект документларына РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсе нигезендә экспертиза үткәрелергә тиеш булса, капиталь төзелеш объектының проект документларына эксперизаның уңай бәяләмәсе (РФ Шәһәр |

| | |
|---|---|
| | төзелеше кодексының 12.1 маддәсендә каралган очракта төзелешнең аерым этапларына карата) яки аның сканерланган күчермәсе (электрон рәвештә тутырганда);<br>9) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 3.4 бүлегендә каралган очракларда, проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе;<br>10) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 6 бүлегендә каралган очракларда, проект документларына дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе;<br>11) модификацияләнгән проект докуменларын файдаланган очракта, әлеге Кодексның 49 маддәсенең 3.5 бүлегендә каралган бәяләмә яки аның сканерланган күчермәсе (электрон рәвештә тутырганда);<br>12) әлеге пунктның 9 пунктчасында күрсәтелгән күп фатирлы йортны реконструкцияләү очракларыннан тыш, капиталь төзелеш объектын реконструкцияләгән очракта, шундый капиталь төзелеш объектының хокукка ия барлык затларының ризалыгы яки аның сканерланган күчермәсе (электрон рәвештә тутырганда);<br>13) күрсәтелгән орган оештыручы функцияләрен һәм вәкаләтләрен яки мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган, шул исәптән реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда (шундый реконструкция үткәрелгәндә), күрсәтелгән объектка китерелгән зыянны каплау шартларын һәм тәртибен билгели торган, хокукка ия заты булып дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе, дәүләт (муниципаль) бюджет яки автономияле учреждениесе торган дәүләт (муниципаль) милкендәге капиталь төзелеш объектында дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджеттан тыш фондлар белән идарә итү органы яки җирле үзидарә органы |

| | |
|---|---|
| | булып исәпләнгән дәүләт (муниципаль) заказчысы тарафыннан реконструкцияләүне үткәрү турында килешенү яки аның сканерланган күчермәсе (электрон рәвештә тутырганда);<br>14) күпфатирлы йортны реконструкцияләгән очракта күп фатирлы йорттагы торак һәм машина урыны милекчеләренең гомуми җыелышының торак законнары нигезендә кабул ителгән карары яки, шундый реконструкция нәтиҗәсендә күп фатирлы йортта гомуми мөлкәт күләме кимегән очракта, күп фатирлы йорттагы барлык торак һәм машина урыны милекчеләренең ризалыгы яки аларның сканерланган күчермәләре (электрон рәвештә тутырганда);<br>15) проект документларына дәүләтнеке булмаган экспертизаның бәяләмәсе бирелгән очракта, проект документларына дәүләтнеке булмаган экспертизаның уңай бәяләмәсен биргән юридик затны аккредитацияләү турында таныклык күчермәсе яки аның сканерланган күчермәсе (электрон рәвештә тутырганда);<br>16) мәдәни мирас объектын саклау эшләрен үткәргәндә, шундый объектның ышанычлылык һәм куркынычсызлыгының конструктив һәм башка характеристикаларына кагылган очракта, мәдәни мирас объектлары турында Россия Федерациясе законнарында каралган документлар яки аларның сканерланган күчермәләре (электрон рәвештә тутырганда).<br><br>Шәхси торак төзелеше объектын төзү, реконструкцияләү максатында төзүче тарафыннан түбәндәгеләр тапшырыла:<br>1) гариза;<br>2) гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ;<br>3) гариза бирүченең вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ;<br>4) җир участогына хокук Бердәм дәүләт |

| | |
|---|---|
| | кучемсез милек реестрында теркәлмәгән булса, аңа хокук билгеләүче документлар;<br>8<br>5) шәхси торак төзелеше объекты урнашкан урынны билгеләп, жир участогын планлаштыруны оештыру схемасы;<br>6) шәхси торак төзелеше объектының тышкы күренешенең тасвирламасы (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 10.2 бүлегендә каралган очрактан тыш, шәхси торак төзелеше объектын төзү яки реконструкцияләү федераль яки региональ әһәмияткә ия тарихи жирлек территориясе чикләрендә планлаштырылган очракта. Капиталь төзелеш объектын төзү яки реконструкцияләү капиталь төзелеш объектының типовой архитектура карары нигезендә планлаштырылган очракта, төзелешкә рөхсәт бирү турындагы гаризада шундый типовой архитектура карары күрсәтелә. Бу очракта объектның тышкы күренеше тасвирламасын теркәү таләп ителми).<br>Капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү өчен рөхсәткә үзгәрешләр керткән очракта, төзүче тарафыннан түбәндәгеләр тапшырыла:<br>1) гариза (әлеге Регламентка 2 нче кушымта);<br>2) гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ;<br>3) гариза бирүченең вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ;<br>4) капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертүне нигезләүче Документта – муниципаль хезмәт нәтиҗәсендә техник хаталар табылган очракта:<br>1) гариза (әлеге Регламентка 3 нче кушымта);<br>2) гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ;<br>3) гариза бирүченең вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ; |

| | |
|---|---|
| | 4) техник хаталы документ – муниципаль хезмәт нәтиҗәсе.<br>Җир участогына хокуклар, җир участогын булдыру турында җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы гариза бирүчегә күчкән очракта, гариза бирүче тарафыннан түбәндәге реквизитларны күрсәтеп белдерү кәгазе (әлеге Регламентка 4 нче кушымта) тапшырыла:<br>1) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 маддәсенең 21.5 бүлегендә күрсәтелгән очракта, шундый җир участокларына хокук билгеләүче документлар;<br>2) җир законнары нигезендә җир участогын булдыру турындагы карарны дәүләт хакимиятенең башкарма органы яки җирле үзидарә органы кабул итсә, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 маддәсенең 21.6 һәм 21.7 бүлекләрендә каралган очракларда җир участокларын булдыру турында карарлар;<br>3) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 маддәсенең 21.7 бүлегендә каралган очракта, капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү планлаштырыла торган җир участогының шәһәр төзелеше планы;<br>4) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 маддәсенең 21.9 бүлегендә каралган очракта, җир асты байлыкларыннан файдалануга хокук бирү турында карар һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне кабат рәсмиләштерү турында карар. |

5) 2.15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре | Муниципаль хезмәтнең һәркем алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>2) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алуның срогын үтәү;<br>3) Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан әлеге | |

| | | |
|---|---|---|
| | регламентны бозу прецедентлары (дәлилле шикаятьләр) булу;<br>4) күпфункцияле үзәк аша муниципаль хезмәт турында консультация алу, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү, муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу мөмкинлеге;<br>5) мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә районның рәсми сайтында kaybici.tatarstan.ru , Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>6) Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша электрон рәвештә гариза бирү, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге.<br>7) Башкарма комитет хезмәткәрләренә запись яки КФҮкә язылу Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да мөмкин uslugi.tatarstan.ru ( техник мөмкинлекләр булганда) | |

6) 2.16 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтүнең үзенчәлекләре | Электрон рәвештә муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультацияне шәһәрнең Интернет кабул итүе, шәһәрнең рәсми сайты яки Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Муниципаль хезмәт түбәндәге очракларда электрон формада күрсәтелә:<br>- капиталь төзелеш объекты проект документациясе экспертизасының уңай бәяләмәсе электрон формада бирелгән булса | |

| | | |
|---|---|---|
| | (электрон –цифрлы имза белән расланган);<br>- капиталь төзелеш объекты проект документациясе һәм (яки) мондый проект документациясе әзерләү өчен башкарылган инженер эшләре нәтиҗәләре, шулай ук проект документациясе дәүләт экспертизасы үткәрү өчен кирәк булган башка документлар электрон формада бирелгән булса.<br>Гариза бирүче шәхесен раслаучы документ яки аның ЕСИАдан алынган реквизитлары стандарттан түбән булмаса (электрон формада бирелгән булса).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүгә электрон формадагы гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гади электрон имза белән имзалана.<br>Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алынган гаризаны теркәү «Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат үзәге» мәгълүмат системасының эчке файдаланучыларыөчен электрон төрдә дәүләт,муниципаль һәм социаль әһәмияткә ия хезмәтләр күрсәтү өчен модульдә гамәлгә ашырыла.<br>Гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелгәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турындагы<br>мәгълүмат, шулай ук муницпаль хезмәт нәтиҗәсе турындагы мәгълүмат элетрон рәвештә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында | |

| | | |
|---|---|---|
| | гариза бирүченең шәхси кабинетына җибәрелә, гариза бирүче белән башкаручы арасында турыдан-туры эшчәнлек таләп ителми. | |

7) 3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

8) «3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр тәртибен тасвирлау

3.1.1. Гариза шәхсән бирелгәндә муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.1.1.2 Гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә бирелгән очракта:

1) гариза бирүче тарафыннан Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында электрон рәвештәге гаризаны тутыру;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) нәтиҗә турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында гариза бирүченең шәхси кабинетына җибәрү.»

9) 3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

10) «3.3. Гариза бирүче гаризаны түбәндге ысуллар белән бирергә мөмкин:

1) әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны теркәп, шәхсән яки ышанычлы зат аша язма рәвештә Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә (алга таба – эш кәгазьләрен алып бару идарәсе);

2) әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны теркәп, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә.

9) 3.3.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Электрон рәвештәге муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә шәһәрнең Интернет-кабул итүе аша, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелергә мөмкин. Электрон рәвештә кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла»;

10) 3.3.2. пунктының атамасын түбәндәге редакциядә шәрехләргә «Гаризаны кабул итү һәм теркәү (шәхсән тапшырганда)».

11) 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Гариза бирүче Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шул исәптән түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны, комплексы запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирелергә мөмкин;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Кайбыч муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Кайбыч муниципаль районы берәмлегенең норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигез федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Кайбыч муниципаль районы берәмлегенең башка норматив хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту.

210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирелергә мөмкин;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Кайбыч муниципаль районы

бирәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирелергә мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату.

210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирелергә мөмкин.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазь йөрткечтә яки электрон төрдә Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) (алга таба – күпфункцияле үзәкне оештыручы), шулай ук 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларга бирелә.

Башкарма комитет Җитәкчесенең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр Кайбыч муниципаль районының район Советына бирелә. Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр шул күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне оештыручыга яки Татарстан 15 Республикасының норматив хокукый актлары белән вәкаләтләнгән вазыйфаи затка бирелә. 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр шул оешмаларның җитәкчеләренә бирелә.

Шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүматтелекоммуникация челтәреннән, Кайбыч муниципаль районы рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр

порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

Әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүматтелекоммуникация челтәреннән, әлеге оешмаларның рәсми сайтларыннан, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат, гариза бирүче – юридик затның урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (лары), электрон почта адресы (лары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

Гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлгән документлар исемлеге язып куела.

5.4. Шикаять гариза бирүче яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

5.5. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә.

Башкарма комитетның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш

көне эчендә.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хокуый актларында түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.

5.7. Шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап, әлеге Регламентта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон төрдә җибәрелә.

5.8. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, Башкарма комитет Җитәкчесе, ачыкланган кимчелекләрне бетерү һәм булдырмау максатында кабул ителергә тиешле чараларны билгели.

5.9. Шикаятьләрне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм информацион-телекоммуник-ацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында” урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х. Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров